| ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ<br>ВЕТЕРИНАРИИ<br>КАБИНЕТА МИНИСТРОВ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНИСТРЛАР<br>КАБИНЕТЫНЫҢ<br>БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.10.2020 Казан ш. № 135-од

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган, Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына кергән органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган ветеринария өлкәсендәге белгечләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 12 ноябрендәге 179-од номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 16 маендагы 395 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган, Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына кергән органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган ветеринария өлкәсендәге белгечләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 12 ноябрендәге 179-од номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2012 елның 10 мартындагы 202 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе турындагы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге карары нигезендә боерык бирәм:»;

Әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган, Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына кергән органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган ветеринария өлкәсендәге белгечләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Ветеринария эшен оештыру бүлегенә әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе сайтында урнаштырырга.

3. Хокук бүлегенә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми сайтында (PRAVO.TATARSTAN.RU) рәсми рәвештә бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Г.Г.Мотыйгуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының Баш
ветеринария идарәсенең 2019
елның 12 ноябрендәге 179-од
номерлы боерыгы белән
расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты Баш
ветеринария идарәсенең 2020
елның 19 октябрендәге
135-од номерлы боерыгы
редакциясендә)

# Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган, Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына кергән органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган ветеринария өлкәсендәге белгечләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Административ регламент (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган, Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына кергән органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган ветеринария өлкәсендәге белгечләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр — Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган, Россия Федерациясе дәүләт ветеринария хезмәте системасына кергән органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган, югары яки урта ветеринария белеме булган физик затлар (алга таба – Мөрәҗәгать итүче).

1.3. Әлеге Административ регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән затларның мәнфәгатьләрен үз вәкаләтләрен таныклый торган документ нигезендә яки законнар нигезендә Мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эшли торган башка затлар да (законлы вәкилләр) (алга таба – Мөрәҗәгать итүченең вәкиле) белдерә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе (алга таба – Идарә) тарафыннан күрсәтелә.

1.4.1. Идарәнең урнашкан урыны: Казан шәһәре, Федосеев урамы, 36.

Идарәнең эш графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбедән тыш, 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән кала, Идарәнең эш сәгатьләрендә.

Җәмәгать транспортында «Университет» тукталышына кадәр килергә кирәк:

22, 28, 28а, 89 номерлы автобуслар.

Кертү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

1.4.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы Рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына кергән Идарәнең рәсми сайты адресы (алга таба – «Интернет» челтәре һәм Идарәнең рәсми сайты): http://guv.tatar.ru, электрон почта адресы: guv.tatar.ru.

1.4.3. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) «Интернет» челтәре аша;

«Интернет» челтәрендәге Идарәнең рәсми сайтында (http://guv.tatar.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

2) Идарәгә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон буенча);

3) Идарәгә язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә.

Идарәнең Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» челтәрендә Идарәнең рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

1.4.4. Идарәнең урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, шулай ук Идарәнең электрон почтасы адресы турында мәгълүмат Идарәнең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын да күрсәтеп) Идарәнең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.6. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

административ регламент – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләре нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү процессында башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган административ процедураларның (гамәлләрнең) срокларын һәм эзлеклелеген билгели торган законнар нигезендә билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча вәкаләтләр бирелгән Татарстан Республикасы дәүләт

хакимияте башкарма органының (алга таба – башкарма хакимият органы) норматив хокукый акты;

дәүләт хезмәте – федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда дәүләт хакимияте башкарма органының, җирле үзидарә органының функцияләрен гамәлгәашыру эшчәнлеге, ул дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән вәкаләтләре чигендә Мөрәҗәгать итүчеләрнең рәсми мөрәҗәгатьләре буенча гамәлгә ашырыла;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе бозылуга шикаять (алга таба – шикаять) – Мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең башкарма хакимият органы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, башкарма хакимият органы вазыйфаи заты, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яисә 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә каралган оешмалар яки аларның хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдаланган вакытта аның бозылган хокукларын яки законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турындагы таләбе;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автономияле учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

«бер тәрәзә» принцибы – Мөрәҗәгать итүче дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында тиешле рәсми мөрәҗәгать белән яки 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгать белән бер мәртәбә мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтелә торган, ә дәүләт хезмәте күрсәтә торган органнар яки муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар белән хезмәттәшлек итү Мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка гына, норматив хокукый актларга һәм хезмәттәшлек итү турындагы килешүгә туры китереп, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша гамәлгә ашырыла торган принцип;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның, мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең

төгәлсезлегенә китергән хата (язу хатасы, басма хата, грамматик яки арифметик хата йә шуңа охшаш хата);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – дәүләт хезмәте күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пунктында каралган рәсми мөрәҗәгать. Гаризаларның киңәш ителә торган рәвешләре әлеге Административ регламентның 1 нче, 5 нче, 6 нчы кушымталарында китерелде.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы | Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче Россия Федерациясе дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган ветеринария өлкәсе белгечләрен теркәү (алга таба – теркәү) | «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 1 статьясының 3 өлеше, 3 статьясы (алга таба – 4979-1 номерлы Закон), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2012 елның 10 мартындагы 202 номерлы карары (алга таба – 202 номерлы нигезләмә) |
| 2.2. Башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе | 202 номерлы нигезләмәнең 3.3.37 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Теркәү турында карар яисә теркәүдән баш тарту турында карар, теркәү турындагы карар дубликаты бирү, теркәү турындагы карарны алыштыру. | 4979-1 номерлы законның $1^{1}$ статьясының 3 өлеше |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе | Теркәү (теркәүдән баш тарту) турында карар, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гаризаны һәм документларны теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек чорда кабул ителә.<br>Дубликатны рәсмиләштерү һәм бирү, теркәү турындагы карарны алыштыру әлеге Регламентның 2.5 | |

| | | |
|---|---|---|
| законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар кергән көннән өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документны юллау дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән көнне гаризада (кәгазьдә яисә электрон почта аша) күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып гамәлгә ашырыла. | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | Әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән форма буенча гариза.<br>Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:<br>югары яки урта ветеринария белемен раслый торган (диплом), шулай ук квалификация күтәрүне раслый торган документларның күчермәләре (булган очракта);<br>3 х 4 сантиметр үлчәмендә ике фото;<br>Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ (паспорт) күчермәсе;<br>вәкилнең Мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документ;<br>Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә белгеч гамәлгә ашырырга ниятләгән ветеринария хезмәтләре исемлеге;<br>Документларның күчермәләре, төп нөсхәләрен күрсәтеп, нотариаль яктан таныкланган булырга тиеш. Төп нөсхәләре беләп күрсәтелгән документларның күчермәләре Идарәдә таныклана.<br>Ветеринария өлкәсендә белгечне теркәү турында дубликат (әлеге Регламентның 5 нче кушымтасы) бирү турындагы гаризага түбәндәге документлар теркәлә:<br>Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган | |

| | | |
|---|---|---|
| | документ (паспорт) күчермәсе;<br>вәкилнең Мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документ;<br>ветеринария өлкәсендә белгечне теркәү турында яраксызга килгән карар (булган очракта).<br>Ветеринария өлкәсендә белгечне теркәү турындагы карарны алыштырганда гаризага (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта) түбәндәге документлар теркәлә:<br>Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ (паспорт) күчермәсе;<br>вәкилнең Мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документ;<br>үзгәрешләрне раслый торган документларның күчермәләре. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуында торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә дә, аларны тапшыру тәртибе | Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестры) өземтә (Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсендә (алга таба – Россия Федераль салым хезмәтенең ТР идарәсендә) алына.<br>Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз ихтыяры белән дә тапшырырга хокуклы.<br>Әлеге документлар Мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Идарә мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен | 1. Документларның вәкаләтле булмаган зат | |

| | | |
|---|---|---|
| зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | тарафыннан тапшырылуы;<br>2. Тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве.<br>3. Гаризада һәм аңа теркәп тапшырыла торган документларда билгеләнгән тәртиптә расланмаган чистарту, өстәп язу урыннары һәм төзәтмәләр булуы. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:<br>мөрәҗәгать итүче тапшырган гаризада һәм документларда тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат булуы;<br>гаризада тапшырылган белешмәләрнең Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәдә булган мәгълүматларга туры килмәве;<br>физик затның (Мөрәҗәгать итүченең) шәхси эшкуар буларак салым органында теркәлмәгән булуы. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен мөрәҗәгать иткәндә чиратта көтү вакыты – 15 (унбиш) минуттан да артмый.<br>Аерым категория мөрәҗәгать итүчеләр өчен чират билгеләнмәгән | Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указының 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да | Гариза һәм документлар килгән көнне.<br>Гариза электрон формада ял көнендә килгәндә – килгән көненнән соңгы эш көнендә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, һаваны кондиционерлау системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы | «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон,<br>Татарстан Республикасы |

| | | |
|---|---|---|
| тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның да чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.<br>Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:<br>бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;<br>объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, бинага керү һәм объектка керү, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;<br>күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;<br>инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 | Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| | июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү;<br>хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.<br>2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1) документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>2) Мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;<br>3) дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы»нда тулы мәгълүмат булу;<br>4) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>5) инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга | |

| | | |
|---|---|---|
| принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^{1}$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән (шул исәптән тулы күләмдә) файдалану мөмкинлеге яки файдалана алмау | комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1) документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;<br>2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытының саклануы;<br>3) дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуларга карата нигезле шикаятьләр булу;<br>4) Мөрәҗәгать итүченең Идарә белгечләре белән бәйләнешкә керү күләме:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза белән документларны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда, турыдан-туры – ике мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>гариза белән документларны почта аша җибәргәндә, – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Мөрәҗәгать итүче белән эшләү озынлыгы – 15 (унбиш) минуттан артык түгел.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша күрсәтелми.<br>Мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге юк.<br>Экстерриториаль принцип һәм комплекслы | |

| | | |
|---|---|---|
| | мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый | |
| 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр | Гаризаны Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы аша электрон формада тапшыру мөмкинлеге бар (алга таба – Интернет-кабул итү системасы).<br>Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша электрон документ формасында гариза бирү мөмкинлеген гамәлгә ашырганнан соң, дәүләт хезмәте нәтиҗәсе электрон рәвештә бирелә. | «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 11 пункты, 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$, $21^2$ статьялары |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә дә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза төзү өлешендә дә;

2) гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) тапшырылган гаризаны һәм аңа теркәп бирелә торган документларны карау. Мөрәҗәгать итүчене теркәү яисә теркәүдән баш тарту турында карар кабул итү.

5) мөрәҗәгать итүченең шәхси эшен формалаштыру һәм Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче Россия Федерациясе дәүләт ветеринария хезмәте системасына керә торган органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булмаган, ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрына мөрәҗәгать итүче турында белешмәләр кертү (алга таба – Ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестры);

6) Мөрәҗәгать итүчене теркәү турында карар рәсмиләштерү һәм бирү (алга таба – теркәү турында карар);

7) югалганы урынына теркәү турында карар дубликаты бирү;

8) техник хаталарны төзәтү;

9) теркәү турындагы карарны алыштыру;

10) Ветеринария өлкәсендә белгечләр реестрына үзгәрешләр кертү; теркәү турындагы карарны алыштыру;

11) Ветеринария өлкәсендә белгечләр реестрыннан Мөрәҗәгать итүчене төшереп калдыру.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, Мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза төзү өлешендә дә.

Мөрәҗәгать итүче Идарәгә шәхсән, почта аша, телефоннан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша һәм (яки) электрон почта ярдәмендә дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече шәхсән, телефоннан, электрон почта һәм (яки) хат белән, Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, Мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, Мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гаризаның рәвеше һәм эчтәлеге буенча һәм Мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән аны рәсмиләштерү өлешендә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Мөрәҗәгать итүче килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаның рәвеше буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә консультацияләү, шулай ук күрсәтелгән ярдәм.

3.3. Гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Административ процедураны башлау өчен Идарәгә гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар керүе нигез булып тора.

Әлеге административ гамәлне үтәү өчен Идарәнең килгән корреспонденцияне исәпкә алу өчен җаваплы вазыйфаи заты җаваплы булып тора.

3.3.2. Документлар Идарәгә турыдан-туры Мөрәҗәгать итүче тарафыннан, аның законлы вәкиле (ышаныч кәгазе нигезендә) тарафыннан тапшырылырга мөмкин, бер урыннан икенче урынга җибәрелгәндә кыйммәтен белдереп һәм салынганнарның исемлеген күрсәтеп, почта юлламасы итеп яки электрон рәвештә җибәрелә.

3.3.3. Идарәнең килгән корреспонденцияне исәпкә алу өчен җаваплы вазыйфаи заты:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган документлар булу-булмавын тикшерә;

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат сыйфатында гариза тапшыручының вәкаләтләрен тикшерә;

әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, документларны кабул итүдә әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган баш тарту нигезләре булган очракта, Идарәнең килгән корреспонденцияне исәпкә алу өчен җаваплы белгече Мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен нигезләр барлыгы турында хәбәр итә һәм аңа, баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, документларны кайтарып бирә. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча баш тарту язмача рәвештә рәсмиләштерелә.

Мөрәҗәгать итүче гариза һәм документларны почта (электрон почта) аша җибәргәндә, Идарәнең килгән корреспонденцияне исәпкә алу өчен җаваплы вазыйфаи заты аңа почта (электрон почта) буенча баш тарту өчен нигезләр эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кире кайтара.

Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Идарәнең килгән корреспонденцияне исәпкә алу өчен җаваплы вазыйфаи заты:

гаризаны кабул итә һәм терки;

документларны кабул итү датасы һәм вакыты, кергәндә беркетелгән номеры турында тамгалап, гариза күчермәсен Мөрәҗәгать итүчегә тапшыра яки почта буенча яки электрон почта (аның ихтыярына карап) аша җибәрә;

гариза белән документларны Идарә җитәкчесенә тапшыра.

Гаризада, кирә торган теркәү номеры һәм документлар килү датасын күрсәтеп, билгеләнгән формадагы штамп куела (электрон рәвештә мөрәҗәгать иткәндә гариза кәгазьдә бастырыла).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Идарә җитәкчесенә теркәлгән документлары белән тапшырылган гариза, гариза белән документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү, Мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.4. Идарә җитәкчесе гариза белән документлар пакетын алган көнне, аларны Идарәнең хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затына үтәү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Идарәнең хезмәт күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затына җибәрелгән, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган гариза һәм документлар.

3.4. Тапшырылган гаризаны һәм аңа теркәп бирелә торган документларны карау. Мөрәҗәгать итүчене теркәү яисә теркәүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.4.1. Административ процедураны башлап җибәрү өчен Идарәнең хезмәт күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затының Мөрәҗәгать итүче тапшырган гариза һәм документларны алуы нигез булып тора.

Әлеге административ эшне башкару өчен Идарәнең ветеринария эшен оештыру бүлегенең вазыйфаи заты җаваплы булып тора.

3.4.2. Идарәнең хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи заты әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә Мөрәҗәгать итүче тапшырган гаризаның һәм документларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Идарәнең вазыйфаи заты Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган гаризаны һәм документларны алганнан соң, бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаның һәм документларның тулы һәм дөрес булу-булмавына карата үткәрелгән тикшерү.

3.4.3. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба – ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы) аша дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар булган органнарга җибәрү.

3.4.3.1. Идарәнең хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи заты ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар бирү турында рәсми мөрәҗәгать җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Идарәнең вазыйфаи заты Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган гаризаны һәм документларны алганнан соң, бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша җибәрелгән мәгълүматлар (документлар) бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.4. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматны) бирә яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында белдерү (алга таба – документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында белдерү)

җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура, законнарда билгеләнгән срокларда, җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә мәгълүмат белән тәэмин итүче зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: вазыйфаи затка җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яки баш тарту турында белдерү.

3.4.5. Физик зат (Мөрәҗәгать итүче) шәхси эшкуар сыйфатында салым органында теркәлмәгән очракта, Мөрәҗәгать итүче тапшырган гариза белән документларда тулы һәм (яки) төгәл булмаган белешмәләр булганда, гаризадагы белешмәләр Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган белешмәләргә туры килмәсә, Идарәнең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи заты, әлеге Регламентның 2.8 пунктына таянып, карар кабул итү нигезен күрсәтеп, Мөрәҗәгать итүчене теркәүдән баш тарту турында карар әзерли, ул Идарә җитәкчесе тарафыннан имзалана һәм Мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә.

Теркәүдән баш тарту турындагы карар, документларны теркәп, Мөрәҗәгать итүчегә почта аша яки электрон формада аны теркәлгән көннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

Теркәүдән баш тарту турында карар кабул итү Мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламент нигезләмәләре нигезендә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кабат мөрәҗәгать итүгә киртә булып тормый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза белән документларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшергән көннән соң яисә Идарәнең вазыйфаи заты ведомствоара хезмәттәшлек органнарыннан (Россия Федераль салым хезмәтенең ТР идарәсе) гаризада тапшырылган белешмәләрнең Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләргә туры килмәве турында яисә физик затның (Мөрәҗәгать итүченең) салым органында шәхси эшкуар буларак теркәлмәве турында җавап алынган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән теркәүдән баш тарту турында карар.

3.4.6. Гаризада һәм документларда тапшырылган белешмәләрнең тулылыгына һәм дөреслелегенә уздырылган тикшерү уңай нәтиҗә биргән очракта, шулай ук күрсәтелгән белешмәләр Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтәдәге белешмәләргә туры килгән очракта, Идарәнең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи заты Мөрәҗәгать итүчене ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрына кертү турында карар әзерли һәм имзалау өчен Идарә җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Идарәнең вазыйфаи заты ведомствоара электрон хезмәттәшлек органнарыннан (Россия Федераль салым хезмәтенең ТР идарәсе) гаризада күрсәтелгән белешмәләрнең Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтәдәге белешмәләргә туры килүе турында җавап алынган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Идарә җитәкчесе тарафыннан имзаланган Мөрәҗәгать итүчене ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрына кертү турында карар.

3.5. Мөрәҗәгать итүченең шәхси эшен формалаштыру һәм Мөрәҗәгать итүче турында ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрына белешмәләр кертү.

3.5.1. Мөрәҗәгать итүчене ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрына кертү турында Идарә җитәкчесе карары административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

Әлеге административ эшне башкару өчен Идарәнең ветеринария эшен оештыру бүлегенең вазыйфаи заты җаваплы булып тора.

3.5.2. Ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрына язу кертү өчен Идарәнең хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи заты Мөрәҗәгать итүченең шәхси эшен, кертелгән документлар исемлеге белән формалаштыра.

Ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрына түбәндәгеләр кертелә:

Мөрәҗәгать итүченең теркәү номеры;

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме;

Мөрәҗәгать итүчене дәүләт реестрына кертү датасы;

Мөрәҗәгать итүченең дәүләт теркәве турында таныклык номеры;

Мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны;

Мөрәҗәгать итүчене Ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрыннан төшереп калдыру датасы һәм нигезе.

Ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрының киңәш ителгән формасы әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән.

Ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестры кәгазьдә һәм электрон формада алып барыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Мөрәҗәгать итүчене ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрына кертү турында карарга кул куйган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрына кертелгән Мөрәҗәгать итүче турындагы язу.

3.6. Теркәү турында карарны рәсмиләштерү һәм тапшыру.

3.6.1. Ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрына Мөрәҗәгать итүче турында язу кертү административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

Әлеге административ эшне башкару өчен Идарәнең ветеринария эшен оештыру бүлегенең вазыйфаи заты җаваплы булып тора.

3.6.2. Идарәнең хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи заты теркәү турында карарны рәсмиләштерә һәм аны Идарә җитәкчесенә карап тикшерү өчен тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Мөрәҗәгать итүче турындагы язуны ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрына керткәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәсмиләштерелгән һәм Идарә җитәкчесе тарафыннан кул куелган теркәү турында карар.

3.6.3. Идарәнең хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи заты теркәү турында карар рәсмиләштерелгәннән соң бер эш көненнән соңга калмыйча Мөрәҗәгать итүчегә телефон аша яисә электрон формада карарны алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Теркәү турындагы карарны бирү турыдан-туры Мөрәҗәгать итүчегә

Идарәнең вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла. Теркәү турындагы карарның тәкъдим ителә торган формасы әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән.

Теркәү турында карар тапшырылганда вәкаләтле дәүләт хезмәткәре Мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен тикшерә.

Теркәү турында карарны тапшыру факты тапшырылган карарлар журналында теркәлә. Мөрәҗәгать итүче теркәү турында карарны кулга алу факты турында тапшырылган карарлар журналында имза сала. Тапшырылган карарлар журналының тәкъдим ителгән формасы әлеге Регламентка 4 нче кушымтада күрсәтелгән.

Теркәү турында карар бердәнбер нөсхәдә бирелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Мөрәҗәгать итүче теркәү турындагы карарны тапшыру турында мөрәҗәгать иткән вакыттан башлап 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Мөрәҗәгать итүчене теркәү турында рәсмиләштерелгән һәм тапшырылган карар.

3.7. Югалганы урынына теркәү турында карар дубликаты бирү.

3.7.1. Административ процедураны башлау өчен Идарәгә Мөрәҗәгать итүчедән югалганы урынына теркәү турындагы карар дубликатын бирү турында язмача гариза керүе нигез булып тора.

Әлеге административ эшне башкару өчен Идарәнең ветеринария эшен оештыру бүлегенең вазыйфаи заты җаваплы булып тора.

3.7.2. Теркәү турындагы карар югалган очракта язмача гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру нигезендә Мөрәҗәгать итүчегә теркәү турындагы карар дубликаты бирелә.

Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентка карата 5 нче кушымтада китерелде.

Теркәү турындагы югалган карар урынына аның дубликатын шәхсән Мөрәҗәгать итүчегә бирү Идарәнең хезмәт күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Мөрәҗәгать итүчедән тиешле документларның күчермәләрен теркәп, тиешле гариза Идарәгә кергән көннән алып өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: әзерләнгән һәм Мөрәҗәгать итүчегә бирелгән теркәү турында карар дубликаты.

3.8. Техник хата җибәрелгән очракта, теркәү турындагы карарны төзәтү һәм алмаштыру

3.8.1. Административ процедураны башлау өчен Мөрәҗәгать итүчедән Идарәгә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү кирәклеге турында язмача гариза керүе нигез булып тора.

Әлеге административ эшне башкару өчен Идарәнең ветеринария эшен оештыру бүлегенең вазыйфаи заты җаваплы булып тора.

3.8.2. Техник хата җибәрелгән очракта теркәү турындагы карарны төзәтү һәм алмаштыру Мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарәгә әлеге Регламентның 8 нче кушымтасына ярашлы форма буенча техник хатаны төзәтү турында тапшырылган (җибәрелгән) гариза нигезендә гамәлгә ашырыла.

Идарәнең хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи заты Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган гаризаны карый һәм гаризада күрсәтелгән белешмәләрне, кергән корреспонденцияне теркәү журналында тиешле гаризаны теркәгән көннән алып ике эш көненнән дә артмаган вакытта, әлеге Регламентның 3.3-3.8 пунктларында каралган тәртиптә тикшерә.

Карар кабул итү критерие – элек бирелгән карарда ялгышлар һәм (яки) хаталар булуы яки булмавы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән карарда ялгышлар һәм хаталар җибәрелгәнлеге турында ачыкланган очракта, Идарәнең хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи заты күрсәтелгән карарны төзәтә һәм алмаштыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән карарда ялгышлар һәм хаталар булмаган очракта, Идарәнең хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи заты, мондый ялгышларның һәм хаталарның булмавы турында Мөрәҗәгать итүчегә язмача хәбәр итә.

Теркәү турында төзәтелгән карарны шәхсән Мөрәҗәгать итүчегә тапшыру яки аны бирүдән баш тарту Идарәнең хезмәт күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура тиешле гаризаны теркәгән көннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: элек бирелгәне урынына алмаш итеп теркәү турында төзәтелгән, әзерләнгән һәм Мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган карар яки мондый ялгышларның һәм (яки) хаталарның булмавы турында юлланган җавап.

3.9. Ветеринария өлкәсендә белгечләр реестрына үзгәрешләр кертү; Теркәү турындагы карарны алыштыру.

3.9.1. Административ процедураны башлау өчен Мөрәҗәгать итүчедән әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп Идарәгә гариза керүе нигез булып тора.

Әлеге административ эшне башкару өчен Идарәнең ветеринария эшен оештыру бүлегенең вазыйфаи заты җаваплы булып тора.

3.9.2. Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урыны үзгәргән очракта, шулай ук эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны адресы үзгәргән яки эшчәнлек туктатылган очракта, Мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән үзгәрешләр турында әлеге Регламентның 3.3-3.8 пунктларында билгеләнгән тәртиптә теркәүче органга (үзгәрешләрне раслый торагн документларның күчермәләрен теркәп) хәбәр итәргә тиеш.

Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентка карата 6 нчы кушымтада китерелде.

Ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрына үзгәрешләр кертүне һәм теркәү турындагы карарны алыштыруны Идарәнең хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи заты башкара.

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урыны, шулай ук эшкуарлык эшчәнлеген башкару урыны адресы үзгәргән яки эшкуарлык эшчәнлеге туктатылган очракларда, ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрына үзгәрешләр кертү, шулай ук теркәү турында тапшыру өчен яңа карар әзерләү зарурлыгы карар кабул итү өчен критерий булып тора.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Мөрәҗәгать итүчедән

үзгәрешләрне раслый торган документларның күчермәләрен теркәп, тиешле гариза Идарәгә кергән көннән алып өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Мөрәҗәгать итүче турында ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрына кертелгән үзгәрешләр, теркәү турында әзерләнгән һәм Мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган яңа карар.

3.10. Ветеринария өлкәсендә белгечләр реестрыннан Мөрәҗәгать итүчене төшереп калдыру.

3.10.1. Ветеринария эше өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеген туктату турында гариза бирү административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

Әлеге административ эшне башкару өчен Идарәнең ветеринария эшен оештыру бүлегенең вазыйфаи заты җаваплы булып тора.

3.10.2. Гариза турыдан-туры Мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарәгә тапшырылырга, бер урыннан икенче урынга җибәрелгәндә белдерелгән кыйммәтен һәм салынган әйберләрнең исемлеген күрсәтеп, почта юлламасы итеп яки электрон рәвештә җибәрелә.

Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентка карата 7 нче кушымтада китерелде.

3.10.3. Документлар кергән көнне Идарәнең кергән корреспонденцияне исәпкә алу өчен җаваплы вазыйфаи заты барлык документларны Идарә җитәкчесенә тапшыра.

Идарә җитәкчесе гаризаны теркәгән көннән башлап биш эш көне узганчы Мөрәҗәгать итүчене ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрыннан төшереп калдыру турында карар кабул итә һәм гаризаны Идарәнең хезмәт күрсәтү өчен җаваплы булган бүлеге белгеченә ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрына тиешле язуны кертү өчен юллый. Идарәнең хезмәт күрсәтү өчен җаваплы булган бүлеге белгече бер эш көне эчендә ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрына Мөрәҗәгать итүчене төшереп калдыру турында язу кертә.

Ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрына Мөрәҗәгать итүчене төшереп калдыру турында язу кертелгәннән соң, Идарәнең хезмәт күрсәтү өчен җаваплы булган бүлеге белгече ике эш көне дәвамында тиешле белдерүне әзерли һәм аны Идарә җитәкчесенә кул кую өчен җибәрә.

Имзаланганнан соң белдерү ике эш көне эчендә почта юлламасы итеп һәм, аның ихтыярына карап, электрон почта ярдәмендә Мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүчедән ветеринария эше өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеген туктату турында гариза керүе карар кабул итү критерие булып тора.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Мөрәҗәгать итүчедән Идарәгә ветеринария эше өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеген туктату турында гариза кергән көннән соң 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрына кертелгән, Мөрәҗәгать итүчене төшереп калдыру турында язу. Ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрыннан төшереп калдыру турында әзерләнгән һәм Мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән белдерү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Регламент һәм дәүләт хезмәте үтәлешенә карата таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актларның нигезләмәләре үтәлүенә һәм башкарылуына карата, шулай ук җаваплы затлар тарафыннан карарлар кабул ителүгә агымдагы контрольлек Идарә җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Агымдагы контрольлек дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү формасында башкарыла.

4.3. Тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Планлы тикшерүләр эш планнары нигезендә башкарыла. Планнан тыш тикшерүләр Мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча үткәрелә.

4.4. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә Мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Идарә эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Министрлык, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр Идарә, Идарәнең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи заты яки дәүләт граждан хезмәткәре карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә Идарәгә шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сәбәпле Идарә җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты бозылганда;

3) Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документлар яки мәгълүматлар тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп

ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны Мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда Мөрәҗәгать итүчедән, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Идарәнең рәсми сайтыннан (http://guv.tatar.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/), күпфункцияле үзәк аша җибәрелә ала, шулай ук Мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче шикаятендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки граждан хезмәткәренең исеме;

2) Мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, Мөрәҗәгать итүче – юридик затның (шәхси эшкуарның) урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм Мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат яисә дәүләт хезмәткәре карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.4. Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт хезмәткәренең Мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.7. Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча, Мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, җавапта Мөрәҗәгать итүчегә, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында, Идарәдә гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм, дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында, алга таба Мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, Мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган, Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына кергән органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган ветеринария өлкәсендәге белгечләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе җитәкчесенә
______________________________________
кемнән
___________________________________
______________________________________,
яши торган адрес: _________
______________________________________
Тел./факс: ___________________________
Паспорт: серия _________ №__________
Кем тарафыннан бирелгән:
____________________
______________________________________
Бирелгән датасы: ________________
Даими теркәлү адресы:_______________
______________________________________

ГАРИЗА

Мине – _______________________________________
(Ф.И.А.)
Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган, Россия Федерациясе дәүләт ветеринария хезмәте системасына кергән органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган ветеринария өлкәсе белгече итеп теркәвегез турында үтенәм, ветеринария хезмәтләренең түбәндәге төрләрен күрсәтү буенча: ______________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
(ветеринария хезмәте төрләре күрсәтелә)

Белгечлек буенча эш стажы:___________________________________
(ел, ай)

Теркәү өчен тапшырылган документларның дөреслеген раслыйм.
Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

Документлар җәмгысе _____________ биттә.

________________________________________________________________________

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган режимда да, алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында карарлар кабул итүне дә кертеп, (шәхси белешмәләрне жыюга, системага салуга, туплауга, саклауга, тәгаенләүгә (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә, файдалана алмаслык итүгә, юкка чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләргә) үз ризалыгымны, минем тарафтан вәкил булган затның риза булуы хакында раслыйм.

«___»________ 20__ел. ________________________________ _________________

(физик затның/ физик зат вәкиленең имзасы) (ФИА)

Документлар тапшырылды:
Дата: «_____» ___________20___ ел.

______________/__________________/
(имза) (Фамилия, исем, ата исеме)

Документлар кабул ителде:
Дата: «_____» ______________20___ ел.

_______________/____________________/
(имза) (Фамилия, исем, ата исеме)

## Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү номеры ____________
Гариза һәм документлар
гр.__________________________________________________________________

кабул итте _______________/____________________/______________ 20 __ ел.
(имза) (тулы имза)

Документлар саны ____________ нөсхә____________ бит.

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган, Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына кергән органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган ветеринария өлкәсендәге белгечләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсенең фирма бланкында

Белгечне Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган, Россия Федерациясе дәүләт ветеринария хезмәте системасына кергән органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган ветеринария өлкәсе белгече итеп теркәү турында карар

Бирү датасы «___»__________20___ ел., № _________

Карар бирелде__________________________________________________
(Фамилия, исем, ата исеме)
_____________________________________________________________________
(шәхси эшкуарның атамасы, урнашу урыны)
_____________________________________________________________________
Ветеринария эшчәнлеге төрләре:______________________________________
_____________________________________________________________________

Таныклыкның гамәлдә булу вакыты «__» _________ 20__ ел.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе ________________
(Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)
мөһер урыны

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган, Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына кергән органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган ветеринария өлкәсендәге белгечләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестры

| № т/с | Мөрәҗәгать итүчене теркәү номеры | Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, ата исеме | Мөрәҗәгать итүчене дәүләт реестрына кертү датасы | Мөрәҗәгать итүченең дәүләт теркәве турында таныклык номеры | Мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны адресы | Мөрәҗәгать итүчене ветеринария өлкәсендә белгечләр реестрыннан төшереп калдыру датасы һәм нигезе |
|---|---|---|---|---|---|---|

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган, Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына кергән органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган ветеринария өлкәсендәге белгечләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Бирелгән карарлар журналы

| № т/с | Карар номеры һәм көне | Алыну датасы | Мөрәҗәгать итүченең имзасы | Мөрәҗәгать итүченең тулы имзасы |
|---|---|---|---|---|

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган, Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына кергән органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган ветеринария өлкәсендәге белгечләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

форма

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе җитәкчесенә
________________________________________
кемнән
_____________________________________
________________________________________,
яши торган адрес: _________
________________________________________
Тел./факс: ___________________________
Паспорт: серия _________ №__________
Кем тарафыннан бирелгән:
______________________
________________________________________
Бирелгән датасы: ________________
Даими теркәлү адресы:________________
________________________________________

Ветеринария өлкәсендә белгечне теркәү турында карар дубликатын бирү турында гариза

Ветеринария өлкәсендә белгечне теркәү турындагы карарның юкка чыгуы (яраксызга китерелүе) сәбәпле, миңа әлеге карарның дубликатын бирүегез турында сорыйм.

Гаризага кушымталар:
1. _____________________________________________;
2. _____________________________________________.
Эш итү нигезе
_____________________________________________________________________________
(дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эшләүче затның вәкаләтләрен раслый торган документ реквизитлары)

Мөрәҗәгать итүченең имзасы
Дата

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган, Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына кергән органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган ветеринария өлкәсендәге белгечләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

форма

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе җитәкчесенә

_________________________________________

кемнән

______________________________________

_________________________________________,

яши торган адрес: __________

_________________________________________

Тел./факс: _____________________________

Паспорт: серия __________ №___________

Кем тарафыннан бирелгән:

______________________

_________________________________________

Бирелгән датасы: _________________

Даими теркәлү адресы:________________

_________________________________________

Белгечне теркәү турында карарны алыштыру турында гариза

Фамилия, исем, ата исеме, яшәгән урын, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны адресы үзгәртелүгә, эшчәнлекне туктатуга бәйле рәвештә (кирәклесен сайларга), миңа ветеринария өлкәсендәге белгечне теркәү турында бирелгән карарны алмаштыруыгыз турында үтенәм.

Гаризага кушымталар:

1. ______________________________________________________________________;
2. ______________________________________________________________________.

Эш итү нигезе

_____________________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эшләү вәкаләтен раслаучы документ реквизитлары)

Мөрәҗәгать итүченең имзасы

Дата

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган, Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына кергән органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган ветеринария өлкәсендәге белгечләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе җитәкчесенә
_________________________________________
кемнән
______________________________________
_________________________________________,
яши торган адрес: __________
_________________________________________
Тел./факс: ____________________________
Паспорт: серия __________ №___________
Кем тарафыннан бирелгән:
______________________
_________________________________________
Бирелгән датасы: _________________
Даими теркәлү адресы:________________
_________________________________________

Ветеринария өлкәсендә белгечләр реестрыннан төшереп калдыру турында гариза

Ветеринария эше өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру туктатылуга бәйле рәвештә, мине Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче Россия Федерациясе дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органнар һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган ветеринария өлкәсендәге белгечләр реестрыннан төшереп калдыруыгыз турында үтенәм.

Эш итү нигезе
_____________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эшләү вәкаләтен раслаучы документ реквизитлары)

Мөрәҗәгать итүченең имзасы
Дата

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган, Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына кергән органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган ветеринария өлкәсендәге белгечләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта

(формасы)

Кая

________________________________

(орган исеме,

________________________________

дәүләт хезмәте күрсәтүче)

________________________________

________________________________

(оешма атамасы, адресы (почта һәм (яки) электрон), телефон номеры (булган очракта)

## Техник хатаны төзәтү турында гариза

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм

________________________________________________

(хезмәтнең аталышы)

________________________________________ болай дип күрсәтелгән:

(бирелгән документ)

________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:_____________________________________________

________________________________________________

Техник хатаны төзәтүегез һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегез турында үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

Документның әзер булуы турында миңа түбәндәгечә хәбәр итүегез турында үтенәм

________________________________________________

(хәбәр итү ысулы)

________ ____________________________ ____________________

(дата) (мөрәҗәгать итүче/вәкил имзасы) (Ф.И.А.)

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган, Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына кергән органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган ветеринария өлкәсендәге белгечләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә торган, Россия Федерациясе дәүләт ветеринария хезмәте системасына кергән органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле затлары булып тормаган ветеринария өлкәсе белгечләрен теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган һәм аны күрсәтүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Идарә җитәкчесе | (843) 221-77-47 | guv@tatar.ru |
| Идарә җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы | (843) 221-77-49 | Elena.Ilina@tatar.ru |
| Ветеринария эшен оештыру бүлеге җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы | (843) 221-77-44 | Robert.Habipov@tatar.ru |
| Хокук бүлеге җитәкчесе | (843) 221-75-90 | Azatovich.Artur@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| адрес | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес | Сайт |
|---|---|---|---|---|
| 420014, Казан шәһәре, Ирек мәйданы, 1 | Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм кулланучылар базары идарәсе җитәкчесе урынбасары | (843) 264-76-80 | Harisov@tatar.ru | www.prav.tatarstan.ru |